КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 август г.Казань № 687

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 июль, 591 нче, 2020 ел, 25 июль, 625 нче, 2020 ел, 31 июль, 639 нчы, 2020 ел, 08 август, 669 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2020 ел, 15 июль, 591 нче;

«Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 25 июль, 625 нче;

«Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 31 июль, 639 нчы;

«Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 8 август,  669 нчы;

3. Бу карар 2020 елның 17 августыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 март, 208 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 15 август, 687 нче карары редакциясендә)

Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында

Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу куркынычы белән бәйле һәм «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы идарәсе органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек режимын кертү турында» 2020 елның 19 мартындагы 129 номерлы боерыгы, шулай ук Россия Федерациясе территориясендә яңа коронавирус йогышлы авыруын кисәтү буенча оператив штаб карарларын, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибы карарларын, Татарстан Республикасы буенча Баш дәүләт санитар табибының тәкъдимнәрен (күрсәтмәләрен) тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итүгә, шул исәптән Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы идарәсе органнары һәм көчләре өчен югары әзерлек режимы шартларында, чикләү һәм башка чаралар комплексын гамәлгә ашыру Татарстан Республикасының бөтен территориясендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

2. Гражданнарга үз-үзеңне изоляцияләү режимын үтәргә, кирәксез яшәү (тору) урынын калдырып китмәскә, башка гражданнар белән хезмәттәшлекне максималь дәрәҗәдә чикләргә киңәш итәргә.

3. Төнге клублар (дискотекалар), балалар уен бүлмәләре, балалар күңел ачу үзәкләре, бер үк вакытта 100 дән артмашан кеше катнашындагы ачык мәйданчыкларда чаралар оештырудан һәм үткәрүдән тыш, 2020 елның 26 мартыннан төнге клублар (дискотекалар), балалар уен бүлмәләре, балалар күңел ачу үзәкләре эшчәнлеген санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр туктатып торырга.

4. Санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр түбәндәгеләрне тыярга:

2020 елның 19 мартыннан башлап оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан тәмәке тарту өчен кальяннар бирү, алар карамагындагы объектларда һәм территорияләрдә кальяннар куллану буенча хезмәтләр күрсәтү;

2020 елның 12 маеннан башлап гражданнарның ваклап сату объектларында, хезмәтләр күрсәтү, гыйбадәт биналарында, мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрендә, пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт чараларында, шул исәптән таксида, сулыш органнарын индивидуаль яклау чараларыннан (битлек, респираторлар) файдаланмыйча керү һәм урнашу;

2020 елның 12 маеннан башлап даими пассажирлар һәм багаж ташу, балаларның ялын, аларны савыктыруны һәм кире кайтаруны оештыруда балалар төркемнәре тарафыннан пассажирлар һәм багаж ташу, шулай ук пассажирлар йөртүнең маршруты һәм датасы турында белешмәләрне үз эченә алган туроператорларның федераль реестрына керүче юридик зат тарафыннан пассажирлар йөртү кысаларында пассажирлар һәм багаж ташудан тыш, муниципальара маршрутларда пассажирлар һәм багаж ташудан тыш.

5. Санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр түбәндәгеләрне йөкләргә:

2020 елның 30 мартыннан башлап җәмәгать урыннарында, ваклап сату объектларында, хезмәт күрсәтү объектларында, гыйбадәтханә бүлмәләрендә, биналарда һәм корылмаларда, мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрендә гражданнар арасында 1,5 метрдан да ким булмаган дистанцияне (социаль дистанция) үтәргә;

2020 елның 12 мартыннан башлап оешмалар, шәхси эшмәкәрләр, шулай ук «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы гражданнар үзләре эшчәнлекләрен оештыруга әлеге карарның 1 нче кушымтасында билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итә.

6. Санитар-эпидемиологик хәл яхшырганчыга кадәр рөхсәт ителә дип билгеләргә:

а) 2020 елның 5 июненнән башлап спорт үзәкләре, йөзү бассейннары, фитнесүзәкләр эше, социаль дистанцияне тәэмин итә торган спорт җиһазларын урнаштыру һәм бер үк вакытта булырга мөмкин булган затларның чик санына карата таләпләрне үтәү шарты белән:

спорт белән шөгыльләнү өчен бүлмәдә – бүлмәнең 4 кв. метрына исәпләнгән мәйданында бер кеше (хезмәткәрләрне дә кертеп) исәбеннән билгеләнә торган;

төркем белән шөгыльләнү өчен билгеләнгән бассейн зонасында – тиешле зонаның су көзгесе мәйданының 5 кв. метрына бер кеше (хезмәткәрләрне дә кертеп) исәбеннән билгеләнә торган;

йөзү өчен юллар җиһазландырылган бассейн зонасында – бер кеше (хезмәткәрләрне дә кертеп) юлның су көзгесе мәйданы 10 кв. метрына бер кеше (хезмәткәрләрне дә кертеп) исәбеннән билгеләнә торган;

б) 2020 елның 5 июненнән башлап дини оешмалар тарафыннан бер кеше (руханиларны һәм хезмәткәрләрне дә кертеп) исәбеннән билгеләнә торган дини бүлмәдә, бинада яки корылмада бер үк вакытта булырга мөмкин булган затларның иң чик санына карата таләпләрне үтәү шарты белән, дини оешмалар тарафыннан 4 кв. метр мәйданда дини бүлмәләргә, биналарга һәм корылмаларга бару;

в) 2020 елның 8 июненнән башлап Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсе (алга таба – Роспотребнадзор идарәсе) Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитар табибының 2020 елның 20 маенда расланган «COVID-19 таралу куркынычын саклау шартларында санатор-курорт учреждениеләре эшен оештыру буенча тәкъдимнәр» МР 3.1/2.1.0182-20 методик тәкъдимнәрен үтәү турында алдан хәбәр итү шарты белән, шифаханә-курорт оешмаларында (шифаханәләрдә) гражданнарны кабул итү һәм урнаштыру;

г) 15.06.202020 дән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, шул исәптән алдан язылмыйча, бер үк вакытта мәгълүмат бирү һәм көтү секторында бер кеше (хезмәткәрләрне дә кертеп) исәбеннән билгеләнә торган иң чик санга карата таләпләрне үтәү шарты белән мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү;

к) 2020 елның 15 июленнән башлап катнашучыларның түбәндәге гомуми саны белән никахны дәүләт теркәве:

40 кв. метр һәм кечкенәрәк мәйданлы бүлмәләрдә – 10 кешедән дә артмый;

40 кв. метрдан артык мәйданлы бүлмәләрдә – бүлмә мәйданының 4 кв. метрына бер кеше исәбеннән исәпләнә;

е) 2020 елның 15 июленнән башлап сәүдә залының 4 кв. метр мәйданына бер кеше (хезмәткәрләрне дә кертеп) исәбеннән билгеләнә торган сәүдә объектының сәүдә залында бер үк вакытта бер кеше исәпләнгән сәүдә залында була ала торган затларның иң чик санына карата таләпләрне үтәү шарты белән ваклап сату объектлары эше;

ж) 2020 елның 15 июленнән башлап түбәндәге шартларны үтәгәндә җәмәгать туклануы объектлары эше:

1,5 метр араны дистанцияләүне үтәп, өстәлләр урнаштыру;

бер өстәл артында түгел дүрт кешедән артык урнаштырмау;

бүлмәләрдә урнашкан урыннарның 50 проценттан да артмаганын тәэмин итү.

Банкетка хезмәт күрсәтү рөхсәт ителә:

җәйге һавада стационар җәмәгать туклануы объектлары террасларында – әлеге пунктта билгеләнгән шартларны үтәгәндә, шулай ук мондый веранда (террасалар) мәйданының 4 кв. метрына (хезмәткәрләрне дә кертеп) бер кеше исәбеннән билгеләнә торган затларның чик санына карата таләпләрне үтәгәндә, әмма 50 кешедән артык түгел;

бүлмәләрдә – хезмәт күрсәтү залының 4 кв. метр мәйданына, ләкин 50 кешедән артмаган, һәм тиешле бинада бүтән килүчеләр булмаганда, бер кеше (хезмәткәрләрне дә кертеп) исәбеннән билгеләнә торган затларның чик санына карата таләпләрне, шулай ук әлеге пунктта билгеләнгән шартларны үтәгәндә;

з) 2020 елның 15 июленнән башлап ачык һавада аттракционнар эше;

и) 2020 елның 15 июленнән башлап зоопарклар эше, бер үк вакытта бер кеше (хезмәткәрләрне дә кертеп) исәбеннән билгеләнә торган, аның мәйданының 4 кв. метрына билгеләнгән бинада була ала торган затларның иң чик санына карата таләпләрне үтәү шарты белән;

к) 2020 елның 17 августыннан башлап театрлар, кинотеатрлар (кинозаллар), цирк, концерт заллары эше, тамашачылар залын 50 проценттан да армаган күләмдә тутыруны һәм тамашачыларны тигез утыртуны тәэмин итү шарты белән;

л) 2020 елның 17 августыннан башлап 50 проценттан да артмаган күләмдә тутыруны тәэмин итү шарты белән, аквапарклар эше ;

м) 2020 елның 17 августыннан башлап, әгәр әлеге карарда башкача билгеләнмәгән булса, ял, күңел ачу, тамаша, мәдәни, физкультура, спорт, күргәзмә, мәгърифәтчелек, реклама һәм башка шундый чаралар үткәрү:

ачык мәйданчыкларда – бер үк вакытта катнашучылар саны 100 кешедән артмаганда;

бүлмәләрдә – Роспотребнадзор идарәсенең чараны үткәрүгә җиде көннән дә ким булмаган вакыт эчендә һәм бер кеше (оештыручыларны һәм (яки) хезмәткәрләрне дә кертеп) аның мәйданының 4 кв.метрына, ләкин бер бүлмәдә 50 кешедән дә артмаган бинада бер үк вакытта була ала торган затларның чик санына карата таләпләрне үтәү турында алдан язмача хәбәр итү шартында.

Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан яңа коронавирус инфекциясе таралу шартларында профилактик чараларны үтәүне тәэмин итә торган формада чаралар оештыру һәм үткәрү рөхсәт ителә;

н) 2020 елның 17 августыннан башлап тамашачылар урыннарын 25 проценттан артмаган тулыландыруны һәм тамашачыларны тигез утыртуны тәэмин итү шарты белән тамашачылар катнашында рәсми физкультура һәм рәсми спорт чаралары үткәрү.

7. Әлеге карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән авырулар булган гражданнарга яшәү (тору) урыннарыннан китмәскә киңәш итәргә, түбәндәгеләрдән тыш:

ашыгыч (кичектергесез) медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать итүләр һәм тормышка һәм сәламәтлегенә турыдан-туры янау очраклары;

товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуның якындагы урынына бару;

кешеләр күп була торган урыннарда булудан тыш, йорт хайваннарын йөрү яки урамда йөртү (тору) урынына 100 метрдан артмаган арада йөрү яисә йөртү;

калдыкларны якын-тирәдә калдыклар җыю урынына кадәр чыгару;

дистанцион эш формасына күчерү мөмкинлеге булмаган очракта эш урынына бару һәм кире кайту.

65 яшьтән өлкәнрәк гражданнарга, әлеге пунктның икенче – бишенче абзацларында күрсәтелгән очраклардан тыш, яшәү (тору), фактик урнашу урыннарыннан, шул исәптән бакча җир участокларында урнашкан торак һәм бакча йортларыннан китмәскә. Күрсәтелгән чикләү 2020 елның 29 июненнән 2020 елның 12 июленә кадәр, 2020 елның 13 июленнән 2020 елның 26 июленә кадәр, 2020 елның 27 июленнән 2020 елның 9 августына кадәр, 2020 елның 10 августыннан 2020 елның 23 августына кадәр гамәлдә була һәм эш урынында булу эшнең функциясен тәэмин итү өчен критик яктан мөһим булган оешма һәм хакимият органнары җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә кагылмый.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 март, 208 нче
карарына 1 нче кушымта

Оешмалар, шәхси эшмәкәрләр, шулай ук «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы гражданнар эшчәнлеген оештыруга карата таләпләр

1. Оешмаларга, шәхси эшмәкәрләргә:

1) хезмәткәрләр тарафыннан сулыш органнарын индивидуаль яклау чараларын (битлекләр, ресираторлар) һәм, кирәк булганда, аларның карамагындагы объектларда, территорияләрдә һәм транспорт чараларында кулларны индивидуаль яклау чараларын (перчаткалар) куллануны тәэмин итәргә;

2) гамәлдәге санитар кагыйдәләрне һәм гигиеник нормативларны, шулай ук федераль дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы орган (вазыйфаи зат) күрсәтмәләрен һәм таләпләрен тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә;

3) эш (смена) башланганчы көн саен эшчеләрнең тән температурасын үлчәү үткәрергә һәм аларны респиратор авыру симптомнары (томау, тамак кытыршылану, ютәл) турында сораштыру, шулай ук эш урыннарында һәм (яки) эш бирүче территориясендә дүрт сәгатькә кимендә бер тапкыр эшчеләрнең тән температурасын үлчәү үткәрергә;

4) тән температурасы югары булган, йогышлы авыру билгеләре булган затлар эшләвенә юл куймаска;

5) биналарда гомуми кулланылыштагы урыннарны, җиһазларны, инвентарьны, оештыру техникасын һәм өслекләрне дезинфекция чаралары кулланып дезинфекцияләүне гамәлгә ашырырга;

6) кешеләр урнашкан урыннарда хезмәт урыннарын даими (һәр ике сәгать саен) җилләтергә;

7) гомуми бурычлар һәм җитештерү процесслары белән бәйле булмаган аерым цехлар, участоклар, бүлекләр һәм функциональ эш төркемнәре коллективлары арасында элемтәләрне чикләргә, хезмәткәрләрне төшке аш вакытында һәм ял вакытында ял итәргә күчерү, оешма карамагындагы территориягә, шәхси эшмәкәрләргә чыгу, башка участокларга, бүлекләргә, хезмәт, хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле булмаган урыннарга, бүлекләргә, бүлмәләргә күчүне чикләргә;

8) кулларны тире антисептиклары белән эшкәртү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

9) кискен респиратор вируслы инфекцияләрне профилактикалау турында һәркем керә ала торган урыннарда мәгълүмат урнаштырырга;

10) эш көне тәмамланганнан соң биналарны дезинфекция чаралары кулланып юешләп җыештырырга;

11) оешмаларның яки эшчәнлекнең тиешле төрләренә карата эшләнгән яңа коронавирус йогышын профилактикалау буенча Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең күрсәтмәләрен тайпылышсыз үтәргә;

12) Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе соратуы килгәндә, аның хезмәт функцияләрен үтәүгә бәйле рәвештә коронавирус йогышлы авыруы белән авырган барлык контактлар турында мәгълүматны кичекмәстән тапшырырга, авырган кеше эшләгән эш урыннарын һәм бүлмәләрне дезинфекцияләүне тәэмин итәргә;

13) хезмәткәрләр арасында коронавирус йогышлы авыруын профилактикалау буенча кирәкле чаралар күрергә;

14) корреспонденцияне кабул итү һәм җибәрүне бары тик ведомствоара электрон документ әйләнеше системасы, электрон һәм почта элемтәсе аша гына гамәлгә ашырырга;

15) эшчәнлекне оештыру үзенчәлекләреннән чыгып, санитар-эпидемиологик иминлекне тәэмин итү буенча башка чаралар күрергә;

16) урнашу урыны буенча эш белән тәэмин итү үзәкләренә булган вакансияләр турында, алар барлыкка килгән очракта, белешмәләр бирергә.

2. Әлеге таләпләрнең 1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә өстәмә рәвештә гражданнар белән хезмәттәшлек иткәндә оешмаларга һәм шәхси эшмәкәрләргә:

1) гражданнарның ваклап сату объектларында, хезмәтләр күрсәтү, гыйбадәт биналарында, мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрендә, пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт чараларында, шул исәптән таксида, сулыш органнарын индивидуаль яклау чараларыннан (битлек, респираторлар) файдаланмыйча керү һәм урнашу;

2) бер үк вакытта тиешле бинада (территориядә) яисә чарада булырга мөмкин булган затларның чик санына карата таләпләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карары белән билгеләнгәннән арттыруга юл куймаска;

3) гражданнарны кабул итү, аларга хезмәт күрсәтү максатларында, алдан язылу буенча белән интервал арасында тәмамланганнан соң, киләсе кабул итү башлану белән кимендә 10 минут үткәрү өчен агымдагы дезинфекция һәм җилләтү үткәрергә;

4) хезмәткәрләр тарафыннан сулыш органнарын (битлекләр, ресираторлар) һәм кулларны индивидуаль яклау чараларын (перчаткалар) мәҗбүри куллануны тәэмин итәргә;

5) социаль дистанция саклана торган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карары белән билгеләнгән бер үк вакытта тиешле бинада (территориядә) яки чарада булырга мөмкин булган затларның чик санына карата таләпләр үтәлә торган территорияләрдә гражданнарның, шул исәптән социаль дистанциядә хезмәткәрләрне дә кертеп, махсус тамга төшерү һәм алар карамагындагы объектларда, социаль дистанция үтәүне тәэмин итәргә;

6) кулларны тире антисептиклары белән эшкәртү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

7) биналарда гомуми кулланылыштагы урыннарны, җиһазларны, инвентарьны, оештыру техникасын һәм өслекләрне дезинфекцияләүне, дезинфекция чараларын кулланып, көненә кимендә өч тапкыр гамәлгә ашырырга.

3. Оешмаларга һәм шәхси эшмәкәрләргә түбәндәгеләр киңәш ителә:

эшне күбесенчә дистанцион формада оештырырга;

хезмәткәрләрне дистанцион эш формасына күчергәндә, иң беренче чиратта 65 яшьтән өлкәнрәк хезмәткәрләр һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына 2 нче кушымтада күрсәтелгән авырулары булган гражданнар санын минимальләштерергә;

чит затлар белән элемтәләрне чикләү максатыннан хезмәткәрләрне эш урынына илтүне һәм кире кайтаруны оештырырга.

4. «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы гражданнар үз эшчәнлекләренә кагылышлы өлештә әлеге таләпләрне үтиләр.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 март, 208 нче
карарына 3 нче кушымта

Авырулар исемлеге

1. Эндокрин системасы авыруы – Авыруларның халыкара классификациясе – 10 (АХК-10) нигезендә E10 диагнозы буенча классификацияләнә торган инсулинга бәйле шикәр авыруы.

2. Түбәндәгеләр арасыннан сулыш органнары авырулары:

2.1. Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә J44 диагнозы буенча классификацияләнә торган башка хроник обструктив үпкә авыруы.

2.2. Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә J45 диагнозы буенча классификацияләнә торган астма.

2.3. Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә J47 диагнозы буенча классификацияләнә торган бронхоэктатик авыру.

3. Кан әйләнеше системасы авыруы – Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә I27.2, I27.8, I27.9 диагнозлары буенча классификацияләнә торган үпкә авырулары аркасында йөрәк һәм үпкә кан әйләнеше бозылулары авыруы.

4. Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә Z94 диагнозы буенча классификацияләнә торган трансплантацияләнгән органнар һәм тукымалар булу.

5. Сидек-җенес системасы авыруы – Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә 18.0, 18.3 – 18.5 номерлы диагнозлары буенча классификацияләнә торган 3 – 5 стадияләрдәге хроник бөер авыруы.

6. Түбәндәгеләр арасыннан яман шеш авырулары*:

6.1. Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә C00 – C80, C97 диагнозлары буенча классификацияләнә торган теләсә кайсы локализациядәге, шул исәптән күп санлы мөстәкыйль локализациядәге яман шеш авырулары.

6.2. Авыруларның халыкара классификациясе – 10 нигезендә C81 – C96, D46 диагнозлары буенча классификацияләнә торган кискен лейкозлар, югары дәрәҗәдәге яман шеш авырулы лимфомнар, башка лимфопролифератив авыруларның рецидивлары һәм резистент формалары, хроник акселерация һәм бласт кризы фазаларындагы хроник миелолейкоз, беренчел хроник лейкозлар һәм лимфомнар*.

---

* Өченче клиник төркемгә кертелгәннәрдән тыш (онкологиядә).